ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(V чакырылыш)

**V чакырылышның чираттан тыш утырыш**
**КАРАРЫ**

**№6** **Бәйрәкә ав.** **25 март 2026 ел**

Татарстан Республикасы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2025 елның 23 апрелендәге 6 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 20 мартындагы «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ санлы мунисипаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, 2026 елның 18 февралендәге 02-08-01 санлы протест нигезендә, татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2025 елның 23 апрелендәге 6 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 3.9 маддәсенең 3.9.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль законда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.»

1.2. Нигезләмәнең 3.9 маддәсенең 3.9.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.9.2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәре чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында»гы 230-ФЗ санлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм рәвештә тапшырырга тиеш.»;

1.3. Нигезләмәнең 3.9 маддәсенең 3.9.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.7. 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында муниципаль хезмәткәрләргә белешмәләр һәм 2012 елның 3

декабрендәге «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»гы 230-ФЗ санлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләр, әгәр мондый белешмәләрне тапшырсаң йә тулы булмаган белешмәләрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәт хезмәткәрен эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып торса.»;

1.4. Нигезләмәнең 3.9. маддәсенең 3.9.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге маддәнең 3.9.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге маддәнең 3.9.1 һәм 3.9.2 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә тапшыра.»

1.5. Нигезләмәнең 4.1 маддәсендәге 4.1.3 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы

А.О.Әхмәтшина